Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге Башлыгы

# КАРАРЫ

15 октябрь, 2025 ел № 3

Питрәч муниципаль районының Кибәк Иле авыл җирлегендә гражданнарга үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге Советының 2019 елның 8 ноябрендәге 139 номерлы карары (2021 елның 13 декабрендәге 34 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә белән карар бирәм.

1. Кибәк Иле авыл җирлегенең Кибәк Иле авылында гражданнар җыенын гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча билгеләргә.

Халык җыенын ике этапта үткәрү:

- Халык җыенының беренче этабы 2025 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Тукай урамы, 28 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында узачак. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшел, Нариманов, Яңа, Бакча урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- Халык җыенының икенче этабы 2025 елның 14 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Тукай урамы, 28 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты янында узачак. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Чишмәле, Тукай, Мәктәп урамнары буенча теркәлгән кешеләрне дә кертергә кирәк;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2026 елда Кибәк Иле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем, 2 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп һәм җирле әһәмияткә ия

мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү;

- традицион җирләү урыннарын төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кибәк Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Сәйфетдинов